**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 13 апрель № 250

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 ел, 28 март, ТРЗ-17 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алу кагыйдәләрен һәм тәртибен раслау турында» 2005 ел, 15 апрель, 190 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 2 август, 366 нчы; 2010 ел, 3 февраль, 53 нче; 2011 ел, 12 октябрь, 847 нче; 2013 ел, 16 сентябрь, 659 нчы; 2014 ел, 19 август, 599 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алу кагыйдәләрендә һәм тәртибендә:

6 нчы пунктның өченче абзацындагы «юридик зат» сүзләрен «торак төзелеше үсешен финанслауда катнашучы теләсә кайсы милек рәвешендәге оешма (алга таба – оешма)» сүзләренә алыштырырга;

7 нче пунктта:

икенче абзацтагы «яшәү урыны буенча җирле үзидарә органы башлыгы исеменә яки юридик зат җитәкчесе исеменә» сүзләрен «яшәү урыны буенча җирле үзидарә органы җитәкчесе яки оешма җитәкчесе исеменә» сүзләренә алыштырырга;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнарның социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ рәвешендә исәпкә кую турындагы гаризаларын карау гариза биргән көннән бер ай эчендә җирле үзидарә органнары яки оешмалар җитәкчеләре приказлары белән билгеләнгән вазыйфаи затлар тарафыннан гамәлгә ашырыла. Гариза бирүчегә, бу документларны алу турында, аларның исемлеген һәм җирле үзидарә органнары яки оешмалар алган датаны күрсәтеп, раслама кәгазе бирелә.»;

8 нче пунктта:

беренче абзацтагы «юридик затлар» сүзләрен «оешмала**р**» сүзенә алыштырырга;

бишенче абзацны төшереп калдырырга;

алтынчы абзацтагы «җирле үзидарә органы башлыгы боерыгы» сүзләрен «җирле үзидарә органы җитәкчесе боерыгы яки оешма җитәкчесе приказы» сүзләренә алыштырырга;

9 нчы пунктта:

өченче абзацтагы «юридик затларны» сүзләрен «оешмалар» сүзенә алыштырырга;

дүртенче абзацтагы «җирле үзидарә органнарының» сүзләреннән соң «һәм оешмаларның» сүзләрен өстәргә;

11 нче пунктта:

«11. Исәпкә алу эшен теркәү турындагы җирле үзидарә органы җитәкчесе боерыгы күчермәсен яки оешма җитәкчесе приказы күчермәсен, билгеләнгән форма буенча расланган гаиләне исәпкә алу карточкасын, Гариза бирүче анкетасының ике нөсхәсен теркәп, җирле үзидарә органнары, оешмалар махсуслаштырылган оешмага (Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фондына) җибәрә.»;

өченче абзацка «җирле үзидарә органнары» сүзләреннән соң «һәм оешмалар» сүзләрен өстәргә;

12 нче пунктта:

беренче абзацка «җирле үзидарә органнарыннан» сүзләреннән соң «һәм оешмалардан» сүзләрен өстәргә;

13 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гаиләләрнең башлангыч исемлеге Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую кагыйдәләренең һәм тәртибенең 8 нче пункты нигезендә җирле үзидарә органнары боерыгы яки оешмалар приказы кабул ителгән дата буенча Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары яктылыгында төзелә.»;

17 нче пунктка «җирле үзидарә органнары» сүзләреннән соң «, оешмалар» сүзен өстәргә;

18 нче пунктта:

унберенче абзацка «җирле үзидарә органнарына» сүзләреннән соң «, оешмаларга» сүзен өстәргә;

уникенче абзацка «җирле үзидарә органы» сүзләреннән соң «, оешма» сүзен өстәргә;

унөченче абзацка «җирле үзидарә органы» сүзләреннән соң «, оешма» сүзен өстәргә;

әлеге Кагыйдәләргә һәм тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтадагы «**А**дминистрация башлыгына» сүзләрен – «Җирле үзидарә органы җитәкчесенә» сүзләренә, «Предприятие җитәкчесенә» сүзләрен – «Оешма җитәкчесенә» сүзләренә, «(предприятие исеме)» сүзләрен «(оешма исеме)» сүзләренә алыштырырга;

әлеге Кагыйдәләргә һәм тәртипкә теркәлгән 3 нче кушымтада:

1 нче пунктта:

икенче абзацтагы «җирле үзидарә органы башлыгы яки юридик зат җитәкчесе» сүзләрен «җирле үзидарә органы җитәкчесе яки оешма җитәкчесе» сүзләренә алыштырырга;

егерменче абзацтагы «Федераль теркәү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча баш идарәсендә» сүзләрен «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә» сүзләренә алыштырырга;

әлеге Кагыйдәләргә һәм тәртипкә теркәлгән 4 нче кушымтада:

12 нче пункттагы «юридик затның салым түләүче буларак тәңгәлләштерү саны (ИНН)» сүзләрен «оешманың салым түләүче буларак тәңгәлләштерү саны (ИНН)» сүзләренә алыштырырга;

әлеге Кагыйдәләргә һәм тәртипкә теркәлгән 6 нчы кушымтада:

1.1 нче пунктның беренче абзацына «җирле үзидарә органнары» сүзләреннән соң «яки оешмалар» сүзләрен өстәргә;

2.3 нче пунктта:

беренче абзацтагы «җирле үзидарә органы башлыгы боерыгы» сүзләрен «җирле үзидарә органы җитәкчесе яки оешма җитәкчесе приказы» сүзләренә алыштырырга;

алтынчы абзацтагы «җирле үзидарә органы башлыгы» сүзләрен «җирле үзидарә органы җитәкчесе яки оешма җитәкчесе приказы» сүзләренә алыштырырга;

2.23 нче пунктта:

таблицаның 2 нче юлындагы «(юридик зат милкендә)» сүзләрен «(оешма милкендә)» сүзләренә алыштырырга;

икенче абзацтагы «юридик затлар милкендә» сүзләрен «оешмалар милкендә» сүзләренә алыштырырга;

әлеге Кагыйдәләргә һәм тәртипкә теркәлгән 7 нче кушымтада:

1 бүлектә:

беренче абзацка «җирле үзидарә органнарының торак хезмәтләре» сүзләреннән соң «яки оешма җитәкчесе билгеләгән вазыйфаи затлар» сүзләрен өстәргә;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза бирүче гариза биргәннән, анкета тутырганнан, бу карарда билгеләнгән формалар буенча документларның тулы пакетын керткәннән соң җирле үзидарә органнары яки оешма тарафыннан җирле үзидарә органы боерыгы яки оешма җитәкчесе приказы нигезендә гаиләнең исәпкә алу эшен теркәү турындагы мәсьәлә карала.»;

3 бүлекнең дүртенче абзацына «җирле үзидарә органнарының» сүзләреннән соң «яки оешманың» сүзләрен өстәргә;

әлеге Кагыйдәләргә һәм тәртипкә теркәлгән 8 нче кушымтада:

1.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Иҗтимагый торак комиссияләре җирле үзидарә органнарында һәм оешмаларда төзелә.

Иҗтимагый торак комиссияләре составы җирле үзидарә органы карары яки оешма җитәкчесе приказы белән раслана.»;

2 бүлекнең җиденче абзацындагы «предприятиеләр һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 бүлектә:

өченче һәм дүртенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«иҗтимагый торак комиссиясе рәисе – җирле үзидарә органы җитәкчесе йә оешма җитәкчесе;

иҗтимагый торак комиссиясе рәисе урынбасары – җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары яки оешма җитәкчесе приказы белән билгеләнгән вазыйфаи зат;»;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«социаль ипотека буенча торак урыннар сатып алу өчен гаиләләрне исәпкә алуны һәм исәптә торучы гаиләләр реестрын алып баруны гамәгә ашыруга җирле үзидарә органнары яки оешма җитәкчесе вәкаләт биргән вазыйфаи зат;»;

уникенче абзацтагы «юридик зат» сүзләрен «оешма» сүзенә алыштырырга;

унөченче абзацтагы «предприятиедә,» сүзен төшереп калдырырга;

4.3 нче пункттагы «яки юридик затның» сүзләрен «яки оешма» сүзләренә алыштырырга;

4.6 нчы һәм 4.7 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6. Иҗтимагый торак комиссиясе карарын исәпкә алып, җирле үзидарә органы җитәкчесе гражданнарны социаль ипотека буенча торак сатып алу өчен исәпкә алу турында боерык, оешма җитәкчесе гражданнарны социаль ипотека буенча торак сатып алу өчен исәпкә алу турында приказ чыгара.

4.7. Җирле үзидарә органы яки оешма вәкаләт биргән вазыйфаи зат социаль ипотека буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гаиләләр реестрын төзи, аны җирле үзидарә органы җитәкчесе яки оешма җитәкчесе белән раслый һәм законнар нигезендә махсуслаштырылган оешмага (Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фондына) кертә.»;

әлеге Кагыйдәләргә һәм тәртипкә теркәлгән 9 нчы кушымтадагы «администрация» сүзен – «җитәкче» сүзенә, «башлыгы» сүзен «җитәкчесе» сүзенә алыштырырга;

әлеге Кагыйдәләргә һәм тәртипкә теркәлгән 10 нчы кушымтадагы «башлыгы» сүзен «җитәкчесе» сүзенә алыштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 ел, 27 декабрь, ТРЗ-69 нчы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру һәм республика дәүләт ярдәме кысаларында торак бирү тәртибен камилләштерү буенча алга таба чаралар хакында» 2007 ел, 2 август, 366 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 8 октябрь, 543 нче; 2010 ел, 3 февраль, 53 нче; 2011 ел, 12 октябрь, 847 нче; 2013 ел, 14 май, 321 нче; 2013 ел, 16 сентябрь, 659 нчы; 2013 ел, 29 октябрь, 806 нчы; 2015 ел, 15 гыйнвар, 7 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 нче пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Казан, Яр Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама, Зеленодольск, Алабуга шәһәрләрендә, Лаеш һәм Биектау муниципаль районнарында билгеләнгән ташламалы бәя буенча дәүләт ярдәме белән торак урын биргәндә нормативтан артып китү 20 проценттан күбрәк булмаска тиеш;»;

5 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак төзелешен үстерүне финанслауда катнашучы оешмаларга хезмәткәрләргә торак урынар бирүнең иң чик вакыты турындагы шартны һәм социаль ипотека системасында торак урыннар белән беренче чиратта тәэмин итү буенча югары квалификацияле һәм профессиональ кадрлар өчен квоталар күздә тотуны тәкъдим итәргә.».

әлеге карар белән расланган Гражданнарга социаль ипотека буенча торак урыннар бирү тәртибендә:

1 бүлектә:

1.2 нче пунктның икенче абзацындагы «предприятиеләр» сүзен «оешмалар» сүзенә алыштырырга;

1.4 нче пунктның икенче абзацындагы «предприятиеләр» сүзен «оешмалар» сүзенә алыштырырга;

1.7 нче пунктта:

текст буенча тиешле килешләрдәге «предприятие» сүзен тиешле килешләрдәге «оешма» сүзенә алыштырырга;

икенче абзацтагы «юридик зат белән хезмәт мөнәсәбәтләре» сүзләрен «оешма белән хезмәт мөнәсәбәтләре» сүзләренә алыштырырга;

4 бүлекнең 4.1 нче пунктындагы дүртенче абзацның «предприятиеләр» сүзен «оешмалар» сүзенә алыштырырга;

Социаль ипотека буенча торак сатып алу өчен гражданнар түләүләрен кичектереп тору шартларын һәм вакытларын билгеләү тәртибенә теркәлгән 1 нче кушымтада «Квоталар категориясе» графасындагы «предприятиеләр хезмәткәрләре» сүзләрен «оешмалар хезмәткәрләре» сүзләренә алыштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Арттыру коэффициентларын билгеләү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының республика дәүләт ярдәме кысаларында торак бирү мәсьәләләре турындагы кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 3 февраль, 53 нче карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Арттыру коэффициентын социаль ипотека буенча реализацияләү өчен расланган 1 квадрат метр гомуми мәйдан бәясенә карата 1,5 күләмендә билгеләргә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\250.doc